**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы**
**Югары Шепкә авыл җирлеге Советы**

# КАРАР

**21.07.2021 ел** **№ 35**

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Шепкә авыл җирлеге Советының 2020 елның 10 декабрендәге 16 номерлы "Зәй муниципаль районы Югары Шепкә авыл җирлегенең 2021 елга һәм 2022 һәм 2023 елларның планлы чорына бюджеты турында" карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Шепкә авыл җирлеге Уставы нигезендә, Зәй муниципаль районы Югары Шепкә авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Зәй муниципаль районы Югары Шепкә авыл җирлеге Советының 2020 елның 10 декабрендәге 16 номерлы "Зәй муниципаль районы Югары Шепкә авыл җирлегенең 2021 елга һәм 2022 һәм 2023 елларның планлы чорына бюджеты турында" карарына (2021 елның 20 июндәге 31 номерлы үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 статьяның 1 пунктында:
а) 2 өлештә "8239,4" санын "9887,8" санына алмаштырырга";
б) 2 өлештә "8557,5" санын "10721,3" санына алмаштырырга";
в) авыл җирлегенең бюджет кытлыгы 833,5 сум тәшкил итә.

1.2. 1 нче кушымтаның 1 нче таблицасына "2021 елга Зәй муниципаль районы Югары Шепкә авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары"н әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә һәм редакциядә бәян итәргә;

1.3. 2 нче кушымтаның 2 нче таблицасына "Зәй муниципаль районы Югары Шепкә авыл җирлегенең 2021 нчы елга фаразланган керем күләме" н әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә һәм редакциядә бәян итәргә;

1.4. 5 нче кушымтаның 3 нче таблицасына «2021 нчы елга Зәй муниципаль районы Югары Шепкә авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының ведомство структурасы» әлеге карарга 3 нче кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә һәм

редакциядә бәян итәргә;

1.5. 6 нче кушымтаның 4 нче таблицасына "2021 елга бюджет чыгымнары классификациясенең чыгымнар төрләре бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары, төркемнәре буенча Зәй муниципаль районы Югары Шепкә авыл җирлеге бюджетының бюджет ассигнованиеләрен бүлү"гә үзгәрешләр кертергә һәм әлеге карарның 4 нче кушымтасы нигезендә редакциядә бәян итәргә;

2. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда бастырып чыгарырга, "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталында" (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында "Авыл җирлекләре" бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Югары Шепкә авыл җирлеге башлыгы** **Л.М. Камалиева**